| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ ТУЕМБАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТУЕМБАШ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Туембаш

от «17» июль 2023 ел № 16

**Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында «Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы Туембаш авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Туембаш авыл җирлеге Уставы нигезендә Туембаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2023 елның 01 августында «Кукмара муниципаль районының Туембаш авылы җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы Туембаш авылының гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнарның җыенын 13 сәгатькә 01 августка билгеләргә. Гражданнар җыенын Туембаш авылы, Ленин урамы, Сабантуй үздыру урынында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы Туембаш авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктның унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"- Туембаш мәдәният йортын карап тоту (бильярд өстәле аксессуарлар комплекты белән, проектор, экран сатып алу»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы: И. Ф.Гарипов